# Xäzer Betä Ul

**AIGEL (АИГЕЛ)**

Qoyaşnıñ märcän börtegen
Täñre Diñgezgä büläk itkän
Diñgez qızğan
Diñgez oyalğan
Diñgez büläkne alğan

Qoyaşnıñ utlı börtegen
Täñre Diñgezgä atqan
Ut diñgezne çaqqan
Diñgez qızğan
Diñgez yılağan

Öf it, öf it sin anı
Citez cillär
Öf itsen anı
Xäzer betä ul
Xäzer betä ul
Öf-öf, menä inde awırtmıy la
Menä awırtmıy, menä betä ul

Öf it, öf it sin anı, öf it sin anı
Citez cillär
Öf itsen anı
Xäzer betä ul
Xäzer betä ul
Öf-öf, menä inde awırtmıy la
Menä awırtmıy, menä betä ul

Cil qoyaşnı kötkän
Cil dulap iskän
Cil yarağa örgän
Yılama, citkän
Diñgez yılamıy da bütän
Yılamıy
Diñgez yılamıy, Diñgez kipkän

Ay-ay, qoyaşqay
Diñgezgä işelep töşkän
Diñgez qupqan
Diñgez peşkän
Ay-ay, qoyaşqay batqan urında upqın
Diñgez yüweş
Diñgez salqın

Diñgez Qoyaşnı talağan
Qoyaş suwınğan, yoqlağan
Qoyaş suqır
Su östenä niçek qalqır

Diñgez Qoyaşnı talağan
Qoyaş suwınğan, yoqlağan
Qoyaş suqır
Su östenä niçek qalqır

Üp it, üp it, üp it, sin anı, qara Dulqın
Uyansın ğına, uyansın ğına
Üp-üp

Menä inde tuñmıy la
Menä tuñmıy, menä yoqlamıy

Üp it, üp it, üp it, sin anı, qara Dulqın
Uyansın ğına, uyansın ğına
Üp-üp
Menä inde tuñmıy la
Menä tuñmıy, menä yoqlamıy

Dulqın qoyaşnı yalağan
Qoyaş cılınğan, uyanğan
Sunı qızılğa buyağan
Sunı qızılğa buyağan

Dulqın qoyaşnı yalağan
Qoyaş cılınğan, uyanğan
Sunı qızılğa buyağan
Sunı qızılğa buyağan

Öf it, öf it, öf it, sin anı (öf it sin anı)
Citez cillär
Öf itsen anı
Xäzer betä ul
Xäzer betä ul
Öf-öf, menä inde awırtmıy la
Menä awırtmıy, menä betä ul

Öf it, öf it, öf it
Öf it, öf it, öf it, sin anı (öf it sin anı)
Citez cillär
Öf itsen anı
Xäzer betä ul
Xäzer betä ul
Öf-öf, menä inde awırtmıy la
Menä awırtmıy, menä betä ul


Sponzor: www.srovnavac.cz - vyberte si pojištění online!